МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.10.2017 г.Казань № 229/2-н

Татарстан Республикасы авыл
җирлекләре арасында ел саен үткәрелә
торган республика конкурсы турында

Авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү һәм гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларының абруен арттыру, шулай ук Татарстан Республикасы авыл җирлекләре башлыкларының шәхси хуҗалыкларда терлек баш санын саклап калу буенча эшчәнлеген бәяләү максатларында боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы авыл җирлекләре арасында ел саен республика конкурсы үткәрү турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) юридик мәсьәләләр буенча секторына әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә кую өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Министрлыкның түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

“Татарстанның иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалыгы”, “Иң яхшы яшь авыл гаиләсе” исеменә республика конкурсы турында” 2009 елның 3 ноябрендәге 159/2-пр номерлы;

“Татарстан Республикасы авыл җирлекләре арасында республика конкурсы турында” 2010 елның 31 мартындагы 52/2-пр номерлы;

“ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2009 елның 3 ноябрендәге 159/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” 2010 елның 17 декабрендәге 215/2-пр номерлы.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр М.Г. Әхмәтов

2017 елның 229/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы авыл җирлекләре арасында
ел саен республика конкурсы үткәрү турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы авыл җирлекләре арасында ел саен республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Конкурс ел саен әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә күрсәтелгән номинацияләр буенча конкурс торкемнәре өчен үткәрелә.

1.3. Конкурста катнашуга анкеталар авыл җирендә кече эшкуарлыкны алып баруның алдынгы тәҗрибәсен тарату максатларында халык хуҗалыкларында терлек баш санын булдыру буенча иң яхшы күрсәткечләрне тәэмин иткән авыл җирлекләре башлыкларыннан, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан, Татарстан Республикасы крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан алына.

1.4. Җиңүчеләрнең саны 100 номинантны тәшкил итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы муниципаль районнары авыл җирлекләре башлыклары арасында “Терлекнең баш саны артымын тәэмин итү һәм югары исәбен саклап калу” номинациясе буенча 30 гариза;

Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар арасында “Терлекчелекне үстерү буенча иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык” номинациясе буенча 35 гариза;

Татарстан Республикасы крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыклары арасында “Иң яхшы гаилә терлекчелек фермасы” номинациясе буенча 35 гариза.

1.5. Конкурста катнашуга күрсәтелгән номинацияләрдә җиңгән өчен субсидия алмаган авыл җирлекләре башлыклары, крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыклары, шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыклары кертелә.

1.6. Конкурсны оештыручы – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык).

1.7. Конкурсны үткәрү сроклары, шартлары һәм йомгаклары турында мәгълүмат “Татарстан Республикасы Рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составында Министрлыкның рәсми сайтына (http://agro.tatarstan.ru) “Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр” бүлегенә (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

## II. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдән һәм гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыклары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары абруен арттырудан, шулай ук республика авыл җирлекләре башлыкларының шәхси хуҗалыкларда терлек баш санын саклап калу буенча эшчәнлеген бәяләүдән гыйбарәт.

2.2. Әлеге максатны гамәлгә ашыру өчен түбәндәге бурычлар куелган:

Терлек баш саны артымын тәэмин иткән һәм югары исәбен саклап калган авыл җирлекләре башлыкларын, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарны, крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларын саклап калу;

халыкның һәм авыл җирлекләренең эшкә карата активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру һәм кызыксындыру чаралары булдыру;

авыл җирендә кече эшкуарлыкны үстерүгә булышлык күрсәтү.

## III. Конкурс үткәрү шартлары

3.1. Конкурс ачык. Конкурс буенча сайлап алу тигезлек һәм объективлык принципларына нигезләнә.

3.2. Конкурс оч номинация буенча үткәрелә:

I номинация – Татарстан Республикасы муниципаль районнары авыл җирлекләре башлыклары арасында “Терлекнең баш саны артымын тәэмин итү һәм югары исәбен саклап калу”;

II номинация – Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар арасында “Терлекчелекне үстерү буенча иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык”;

III номинация – Татарстан Республикасы крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыклары арасында “Иң яхшы гаилә терлекчелек фермасы”.

3.2. Конкурста катнашу өчен дәгъва итүчеләр (авыл җирлекләре башлыклары, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар, крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыклары) түбәндәге документлар тапшыралар:

әлеге Нигезләмәгә 1 нче – 3 нче кушымталарда каралган форма буенча үз кулы белән тутырылган йә бастырылган катнашучы анкетасы;

гариза бирүченең шәхесен раслый торган документның күчермәсе;

әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтада каралган форма буенча персональ мәгълүматларны эшкәртүгә рөхсәт;

муниципаль берәмлек авыл җирлеге Советының авыл җирлеге башлыгы буларак кимендә бер ел эш стажын раслый торган авыл җирлеге башлыгының вазыйфага сайланып куелуы турында карары (“Терлекнең баш саны артымын тәэмин итү һәм югары исәбен саклап калу” номинациясе буенча);

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарны хуҗалыклар буенча исәпкә алу кенәгәсеннән хуҗалыкны кимендә бер ел алып баруны раслый торган өземтә (“Терлекчелекне үстерү буенча иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык” номинациясе буенча);

гариза бирүченең үз ихтыяры белән Бердәм дәүләт индивидуаль эшкуарлар реестрыннан крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак кимендә бер ел эш стажын таныклый торган өземтә тапшырыла ("Иң яхшы гаилә терлекчелек фермасы" номинациясе буенча). Әгәр күрсәтелгән документ гариза бирүче тарафыннан үз ихтыяры белән тапшырылмаса, Министрлык аны ведомтсвоара хезмәттәшлек итү тәртибе буенча салым органыннан соратып ала.

3.3. Тапшырылган анкеталарны бәяләүнең төп критериеләре:

"Терлекнең баш саны артымын тәэмин итү һәм югары исәбен саклап калу" номинациясе буенча – авыл җирлегендә терлекнең узган елгы гомуми баш саны буенча чагыштырып караганда, терлекнең (сыер, яшь мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык һәм кәҗә, ат, кош-корт) баш саны арту йә югары исәбе саклану, ул анкета нигезендә билгеләнә торган абсолют күрсәткечләрдән алына. Номинантлар тарафыннан тапшырылган мәгълүмат терлек һәм кош-кортның баш саны, халык хуҗалыкларындагы чәчү мәйданнары күрсәткечләре турында шушы елның 1 октябренә төзелгән рәсми статистика хисабы мәгълүматлары белән чагыштырыла.

"Терлекчелекне үстерү буенча иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык" номинациясе буенча – Татарстан Республикасы муниципаль районының башка шәхси ярдәмче хуҗалыклары белән чагыштырып караганда, хуҗалыктагы иң күп терлек (сыер, яшь мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык һәм кәҗә, ат, кош-корт) баш саны, ул анкета нигезендә билгеләнә торган абсолют күрсәткечләрдән алына. Номинантлар тарафыннан тапшырылган мәгълүмат җирле үзидарә органнары тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалыклар буенча исәпкә алу кенәгәсе өземтәләреннән шушы елның 1 октябренә булган мәгълүматлар белән чагыштырыла.

"Иң яхшы гаилә терлекчелек фермасы" номинациясе буенча – Татарстан Республикасы муниципаль районының башка крестьян (фермер) хуҗалыклары белән чагыштырып караганда, фермер хуҗалыгындагы иң күп терлек (сыер, яшь мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык һәм кәҗә, ат, кош-корт) баш саны, ул анкета нигезендә билгеләнә торган абсолют күрсәткечләрдән алына. Номинантлар тарафыннан тапшырылган мәгълүмат терлекчелек продукциясен җитештерү һәм терлек баш саны, шулай ук өстәмә эш урыннары булдыру турындагы мәгълүмат белән чагыштырыла.

3.4. Терлек баш саны түбәндәге коэффициентлар буенча шартлы баш санына күчерелә: сыерлар – 1,0; яшь мөгезле эре терлек – 0,6; дуңгызлар – 0,3; сарыклар һәм кәҗәләр – 0,2; атлар – 1,0; кош-корт – 0,006.

3.5. Конкурс уздыру шартлары Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

3.6. Әгәр Конкурста катнашуга анкеталар Нигезләмәгә 1 – 4 нче кушымталарда билгеләнгән форма буенча тутырылмаган булса, документлар тулы күләмдә тапшырылмаса яки сроклары бозылып тапшырылса, алар кабул ителмәскә мөмкин.

## VI. Конкурс уздыру тәртибе

4.1. Конкурс 2 этапта үткәрелә:

1 этап - муниципаль (эчке) сайлап алу;

2 этап – Министрлыкка Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тәкъдим иткән кандидатуралар арасыннан сайлап алу.

4.2. Конкурсның номинантларын билгеләү өчен әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында каралган материаллар, муниципаль дәрәҗәдәге комиссия эчке сайлап алуны үткәрү максатыннан, Конкурс игълан ителгән вакыттан алып 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарә) кулдан-кулга тапшырыла.

4.3. Эчке комиссия составы Идарә боерыгы белән раслана. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составы үзгәргән очракта, Идарә боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

4.3.1. Эчке комиссиянең эше, әгъзаларның кимендә яртысы булганда, утырышлар рәвешендә башкарыла.

4.3.2. Эчке комиссия эшенә рәис җитәкчелек итә. Эчке комиссия рәисе булмаган очракта, комиссия рәисе вазыйфаларын башкару конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына йөкләнә.

4.3.3. Кабул ителгән материаллар документлар кабул ителеп беткәннән соң 5 эш көне эчендә эчке комиссия тарафыннан карала.

4.3.4. Эчке комиссия, әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында билгеләнгән материалларны бәяләү критериеләренә нигезләнеп, тапшырылган эшләрне карый һәм номинацияләр буенча номинантларны билгели.

4.3.5. Эчке комиссия карары, ачык рәвештә тавыш биреп, утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының, комиссия рәисенең яки аны алмаштыручы затның күпчелек тавышына нигезләнеп кабул ителә.

4.3.6. Тавышлар тигез булганда, комиссия рәисенең яки аны алмаштыручы затның тавышы хәлиткеч була.

4.3.7. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, комиссия рәисе яки аны алмаштыручы зат һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

4.3.8. Комиссия секретаре конкурс комиссиясе әгъзалары составына керми һәм аның утырышында тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

4.4. Комиссия беркетмәсе белән расланган эчке сайлап алу номинантлары турында мәгълүмат (һәр номинация буенча иң күбе 2 анкета) Татарстан Республикасы Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы (алга таба – БВЭДӘ) аша җибәрелә, документлар пакеты алып барып тапшырыла.

4.5. Кабул ителгән материаллар 10 эш көне эчендә Министрлыкның конкурс комиссиясе каравын тапшырыла.

4.5.1. Конкурс комиссиясе тапшырылган эшләрне әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында билгеләнгән материалларны бәяләү критериеләренә нигезләнеп бәяли һәм номинацияләр буенча җиңүчеләрне билгели.

4.6. Министрлыкның конкурс комиссиясе составы Министрлык боерыгы белән раслана. Конкурс комиссиясе составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составы үзгәргән очракта, Министрлык боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

4.6.1. Конкурс комиссиясе үз эшен әгъзаларының кимендә яртысы булганда утырышлар рәвешендә алып бара.

4.6.2. Конкурс комиссиясе эшенә рәис җитәкчелек итә. Конкурс комиссиясе рәисе булмаган очракта, комиссия рәисе вазыйфаларын башкару конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына йөкләнә.

4.6.3. Конкурс комиссиясе карары, ачык рәвештә тавыш биреп, утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының, комиссия рәисенең яки аны алмаштыручы затның күпчелек тавышына нигезләнеп кабул ителә.

4.6.4. Тавышлар тигез булганда, комиссия рәисенең яки аны алмаштыручы затның тавышы хәлиткеч була.

4.6.5. Конкурс комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, конкурс комиссиясе рәисе яки аны алмаштыручы зат һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

4.6.6. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе әгъзалары составына керми һәм аның утырышында тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

4.6.7. Беркетмә имзаланган вакыттан алып 10 эш көне эчендә конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләрен раслау турында боерык чыгарыла, ул Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

## V. Конкурс йомгаклары һәм аны финанслау

5.1. Конкурс җиңүчеләренә субсидияләр бирү түбәндәгечә башкарыла:

“Терлекнең баш саны артымын тәэмин итү һәм югары исәбен саклап калу” номинациясе буенча – 50 000 күләмендә субсидия һәм диплом;

“Терлекчелекне үстерү буенча иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык” номинациясе буенча – 50 000 күләмендә субсидия һәм диплом;

“Иң яхшы гаилә терлекчелек фермасы” номинациясе буенча – 50 000 күләмендә субсидия һәм диплом.

5.2. Конкурс җиңүчеләрен бүләкләү Татарстан Республикасы муниципаль районнарында авыл халкының эшлекле активлыгына нәтиҗәләр чыгару буенча зона семинар-киңәшмәләре кысаларында башкарыла.

5.3. Субсидияләр бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы авыл җирлекләре арасында ел саен республика конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

**КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:**
Татарстан Республикасы __________ муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

________________________________
фамилиясе, исеме, атасы исеме

________________________________
имза

Мөһер урыны

**РАСЛЫЙМ:**
Татарстан Республикасы __________ муниципаль районы башлыгы

________________________________
фамилиясе, исеме, атасы исеме

________________________________
имза

Мөһер урыны

“Терлекнең баш саны артымын тәэмин итү һәм югары исәбен саклап калу” номинациясе буенча
республика конкурсында катнашучы анкетасы

| Күрсәткечләр исеме | Күрсәткечләр | |
|---|---|---|
| | 1 _______, 20__елга | 1 ______, 20___елга |
| Эшчәнлек алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыклар (алга таба – ШЯХ) саны | | |
| ШЯХ хуҗалык яны җир кишәрлекләренең гомуми мәйданы, гектар | | |
| Индивидуаль эшкуарларның (алга таба – ИЭ) һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларының (алга таба – КФХ) саны | | |
| Эшсез гражданнар саны, барлыгы: | | |
| шул исәптән үз-үзләрен эш белән тәэмин итү программасында катнашучылар | | |
| Шәхси хуҗалыклардагы терлекнең баш саны, баш: | | |
| сыер | | |

| | | |
|---|---|---|
| яшь мөгезле эре терлек | | |
| сарык һәм кәҗә | | |
| дуңгыз | | |
| ат | | |
| кош-корт | | |
| шул исәптән терлек саны, 1 хуҗалыкка (терлек баш саны: ШЯХ санына), баш. | | |
| сыер | | |
| яшь мөгезле эре терлек | | |
| сарык һәм кәҗә | | |
| дуңгыз | | |
| ат | | |
| кош-корт | | |
| Шәхси хуҗалыкларда җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе, центнер | | |
| сөт | | |
| терлек һәм кош-корт ите | | |
| шул исәптән 1 хуҗалыкка (ШЯХ), центнер | | |
| сөт | | |
| терлек һәм кош-корт ите | | |
| шәхси хуҗалыклардан сатылган продукция, центнер | | |
| сөт | | |
| терлек һәм кош-корт ите | | |
| шул исәптән 1 хуҗалыкка (ШЯХ), центнер | | |
| сөт | | |
| терлек һәм кош-корт ите | | |
| Пай җирләренә аренда түләвенең уртача күләме, 1 гектар өчен сум* | | |
| 2006-20___елларда ШЯХ һәм КФХ тарафыннан алынган кредитлар саны, берәмлек | | |
| шул исәптән субсидияләнә торганнар, берәмлек | | |
| 20___елда хуҗалык итүнең кече формаларына алынган дәүләт ярдәме суммасы, мең сум | | |
| шул исәптән алучылар саны турында мәгълүмат, *берәмлек.* | | |

******ашлык фуражы, печән һәм салам бирү, бакча сукалау буенча һәм башка төр хезмәт күрсәтүләрне районнардагы уртача бәяләрне акчага күчереп исәпләргә.*

Авыл җирлеге башлыгы ___________ ______________________ __________________
(имза) (фамилиясе,исеме, атасы исеме) (телефон номеры)

Баш бухгалтер ______________ _______________________ _________________
(имза) (фамилиясе,исеме, атасы исеме) (телефон номеры)

Мөһер урыны

Татарстан Республикасы авыл җирлекләре арасында ел саен республика конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Раслыйм:

**РАСЛЫЙМ:**
Татарстан Республикасы __________
муниципаль районы башлыгы

____________________________________
(фамилиясе,исеме, атасы исеме)

___________________, ____________ел

Мөһер урыны

“Терлекчелекне үстерү буенча иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык”
номинациясе буенча
(крестьян (фермер) хуҗалыклары (алга таба – КФХ) оештырган гаиләләрне исәпкә алмыйча) республика конкурсында
катнашучы анкетасы

Шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгының фамилиясе, исеме, атасы исеме (тулысынча)______________________________________________________________
ШЯХ адресы ______________________________________________________________

ШЯХ үсешенең төп юнәлешләре: (туры килгәненең астына сызарга): сөт терлекчелеге; терлекне үстереп бетерү һәм симертү; дуңгызчылык; сарык үрчетү; ат үрчетү; кәҗә үрчетү; кошчылык.

1. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең төп максаты:

Төп акча чыганагы Әйе □ Юк □
Өстәмә акча эшләү чыганагы Әйе □ Юк □

2.

| Гаиләнең хезмәт ресурслары | Гаилә әгъзалары саны |
|---|---|
| Барлыгы: | |

| | |
|---|---|
| шул исәптән 16 яшькә кадәргеләр | |
| 16-45 яшьлекләр | |
| 45-60 яшьлекләр | |
| шулардан: төп эш урыны – ШЯХ булганнар | |
| 60 яштән өлкәнрәкләр | |

ШЯХ башлыгының төп эш урыны (наем буенча):________________________

3. Утар

| Күрсәткеч | +, - |
|---|---|
| Йортның гомуми мәйданы, квадрат метр | |
| Эшләнү материалы: | |
| а) агач (бүрәнә) | |
| б) кирпеч | |
| Җиһазландырылу: | |
| а) суүткәргеч белән | |
| б) канализация белән | |
| в) электр белән | |
| г) газ белән | |

4. Хуҗалык корылмалары

| Исеме | Мәйдан, квадрат метр |
|---|---|
| Терлек асрау бинасы | |
| Техника саклау бинас | |
| Авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү бинасы | |
| Азык, икмәк-фураж саклау бинасы | |

5. Җир ресурслары

| Исеме | Мәйдан, гектар |
|---|---|

| | |
|---|---|
| Ян җир кишәрлеге | |
| Кыр җир кишәрлекләре (ШЯХ өчен файдаланыла торган арендага алынган печән җирләрен һәм көтүлекләрне кертеп) | |

6. Техник чаралар

| Исеме | Берәмлек саны |
|---|---|
| 18 кВт тан (25 ат көченнән) башланган тракторлар | |
| Трактор прицеплары | |
| Трактор сукалары | |
| Трактор печәнчапкычлары | |
| Мотоблоклар һәм мотокультиваторлар | |
| Йөк автомобильләре | |
| Җиңел автомобильләр | |
| Сөт саву җайланмалары | |
| Он тарту һәм ярма ясау җайланмалары | |
| Сепараторлар | |
| Ыслау җайланмалары | |
| Азык ваклау җайланмалары | |
| Инкубаторлар | |

7. Хайваннарның баш саны:

| Хайван атамасы | Баш саны |
|---|---|

| | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында алдагы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында быелгы ел торышы буенча |
|---|---|---|
| Сыерлар | | |
| Таналар, үгезләр, бозаулаган сыерлар | | |
| Дуңгызлар | | |
| шул исәптән ана һәм ата дуңгызлар | | |
| Сарыклар | | |
| Кәҗәләр | | |
| Атлар | | |
| Зур кош-корт: тавыклар, казлар, үрдәкләр, күркәләр, бытбылдыклар | | |
| Кыйммәтле мехлы җәнлекләр (куяннар) | | |
| Бал корты оялары | | |

8. Терлекчелек продукциясен житештерү һәм сату күләме:

| Исеме | Җитештерелгән, центнер | | Сатылган, центнер/сум *(вакланма аша сумма)* | |
|---|---|---|---|---|
| | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында алдагы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында быелгы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында алдагы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында быелгы ел торышы буенча |
| Сөт | | | | |
| Мөгезле эре терлек ите | | | | |
| Дуңгыз ите | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Сарык ите | | | | |
| Йон | | | | |
| Кош-корт ите | | | | |
| Йомырка | | | | |
| Бал | | | | |

9. Күрсәтелгән түләүле хезмәтләр

| Исеме | Сатылган, сум | |
|---|---|---|
| | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында алдагы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында быелгы ел торышы буенча |
| Башкарылган авыл хуҗалыгы эшләре һәм күрсәтелгән транспорт хезмәтләре | | |

10. Сез хезмәт күрсәтүче авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы әгъзасымы? (туры килмәгән җавапның өстенә сызарга)
□ Әйе □ Юк

11. Банк кредитларыннан файдаланасызмы?

□ Әйе □ Юк

12. Җавап “әйе” булса, кредитны ничә тапкыр алдыгыз? ____________________

13. Алган кредит суммасы, мең сум ____________________________________

14. Кредит буенча түләнгән процентлар очен алынган субсидия, мең сум
_______________________________________________________

ШЯХ башлыгы ________________ ________________________
(имза) (фамилия, исем, атасы исеме)

Дата_________________

Татарстан Республикасы авыл җирлекләре арасында ел саен республика конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Раслыйм:**
Татарстан Республикасы __________
муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе
___________________________________
фамилиясе,исеме, атасы исеме
___________________________________
имза

Мөһер урыны

“Иң яхшы гаилә терлекчелек фермасы” номинациясе буенча
республика конкурсында
катнашучы анкетасы

Гаилә терлекчелек фермасы (алга таба – ГТФ) башлыгының фамилиясе, исеме, атасы исеме (тулысынча)_______________________________________________
ГТФ башлыгы адресы_____________________________________________________
_______________________________________________________________________

ГТФ үсешенең төп юнәлеше: (туры килгәненең астына сызарга) сөт терлекчелеге; терлекне үстереп бетерү һәм симертү; дуңгызчылык; сарык үрчетү; ат үрчетү; кәҗә үрчетү; кошчылык _________ баш.

1. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең төп максаты:
   Төп акча чыганагы Әйе □ Юк □
   Өстәмә акча эшләү чыганагы Әйе □ Юк □

2. Гаиләнең хезмәт ресурслары

| | Гаилә әгъзалары саны |
|---|---|
| Барлыгы: | |
| шул исәптән 16 яшькә кадәргеләр | |
| 16-45 яшьлекләр | |

| | |
|---|---|
| 45-60 яшьлекләр | |
| шулардан: төп эш урыны – ШЯХ булганнар | |
| 60 яшьтән өлкәнрәкләр | |

3. Утар

| Показатель | +, - |
|---|---|
| Йортның гомуми мәйданы, квадрат метр | |
| Эшләнү материалы: | |
| а) агач (бүрәнә) | |
| б) кирпеч | |
| Җиһазландырылу: | |
| а) суүткәргеч белән | |
| б) канализация белән | |
| в) электр белән | |
| г) газ белән | |

4. Хуҗалык корылмалары

| Исеме | Мәйдан, квадрат метр |
|---|---|
| Терлек асрау бинасы | |
| Техника саклау бинас | |
| Авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү бинасы | |
| Азык, икмәк-фураж саклау бинасы | |

5. Җир ресурслары

| Исеме | Мәйдан, гектар |
|---|---|
| Җир, барлыгы | |
| шул исәптән милек буларак | |
| арендада | |
| арендага алынган пай җирләре | |

6. Техник чаралар

| Исеме | Берәмлек саны |
|---|---|
| 18 кВт тан (25 ат көченнән) башланган тракторлар | |
| Трактор прицеплары | |
| Трактор сукалары | |
| Трактор печәнчапкычлары | |

| | |
|---|---|
| Мотоблоклар һәм мотокультиваторлар | |
| Йөк автомобильләре | |
| Җиңел автомобильләр | |
| Сөт саву җайланмалары | |
| Он тарту һәм ярма ясау җайланмалары | |
| Сепараторлар | |
| Ыслау җайланмалары | |
| Азык ваклау җайланмалары | |
| Инкубаторлар | |

7. Чәчү җирләре һәм үсемлекчелек продукциясен җитештерү

| Культура атамасы | Мәйдан, гектар | Җитештерелгән продукция, центнер | | Сатылган, центнер | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында алдагы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында быелгы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында алдагы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында быелгы ел торышы буенча |
| Бөртеклеләр һәм бөртекле-кузаклылар | | | | | |
| Бәрәңге | | | | | |
| Яшелчә культуралары: | | | | | |
| суган | | | | | |
| чөгендер | | | | | |
| кишер | | | | | |
| Ябык грунт (теплица) яшелчә культуралары | | | | | |
| Бакча һәм җиләк культуралары | | | | | |
| Азык | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| культуралары | | | | | |

8. Хайваннарның баш саны

| Хайван атамалары | Баш саны исәбе | |
|---|---|---|
| | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында алдагы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында быелгы ел торышы буенча |
| Сыерлар | | |
| Таналар, үгезләр, бозаулаган сыерлар | | |
| Дуңгызлар | | |
| шул исәптән ана һәм ата дуңгызлар | | |
| Сарыклар | | |
| Кәҗәләр | | |
| Атлар | | |
| Зур кош-корт: тавыклар, казлар, үрдәкләр, күркәләр, бытбылдыклар | | |
| Кыйммәтле мехлы җәнлекләр (куяннар) | | |
| Бал корты оялары | | |

9. Терлекчелек продукциясен житештерү һәм сату күләме:

| Исеме | Җитештерелгән, центнер/сум | | Сатылган, центнер/сум *(вакланма аша сумма)* | |
|---|---|---|---|---|
| | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында алдагы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында быелгы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында алдагы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында быелгы ел торышы буенча |
| Сөт | | | | |
| Мөгезле эре терлек ите | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Дуңгыз ите | | | | |
| Сарык ите | | | | |
| Йон | | | | |
| Кош-корт ите | | | | |
| Йомырка | | | | |
| Бал | | | | |

10.Күрсәтелгән түләүле хезмәтләр

| Исемее | Сатылган, сум | |
|---|---|---|
| | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында алдагы ел торышы буенча | Конкурс игълан ителгән айның 1 числосында быелгы ел торышы буенча |
| Башкарылган авыл хуҗалыгы эшләре һәм күрсәтелгән транспорт хезмәтләре | | |

11.Конкурс игълан ителгән айның 1 числосына быелгы ел торышы буенча җәлеп ителгән ялланган хезмәткәрләр (гаилә әгъзаларыннан тыш) саны, кеше ____________________________________

12.Ялланган хезмәткәргә түләнә торган айлык хезмәт хакы, сум

______________________________________________

13.ГТФ башлыгы тарафыннан түләнгән салымнар суммасы, сум:

20___ елда 20___елда

____________________ ________________________

14.Сез авыл җирлеге халкына нинди дә булса ярдәм күрсәттегезме?

□ Әйе □ Юк

15.Җавап "әйе" булса, нинди ярдәм күрсәтүегезне тулырак языгыз

______________________________________________

______________________________________________

16.Сез хезмәт күрсәтүче авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы әгъзасымы? (туры килмәгән җавапның өстенә сызарга)

□ Әйе □ Юк

17.Банк кредитларыннан файдаланасызмы?

□ Әйе □ Юк

18.Җавап “әйе” булса, кредитны ничә тапкыр алдыгыз____________________

19. Алган кредит суммасы, мең сум____________________________________

20. Кредит буенча түләнгән процентлар өчен алынган субсидия, мең сум
________________________________________________________________

21.Пай хуҗаларыннан арендага алынган пай җирләре өчен аренда түләвенең гомуми күләме, сум, шул исәптән 1 гектар өчен ______________________

ГТФ башлыгы____________________ ________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасы исеме)

Дата ________________________________

Татарстан Республикасы авыл җирлекләре арасында ел саен республика конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

Мин_______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________ __________ № _____________, ____________________
(шәхесне таныклаучы документ, кайда, кем тарафынан һәм кайчан бирелгән)

_________________________________________________________________,
_________________________________________________________________
_______________________________________________ адресы буенча теркәлгән,
гамәлдә
_____________________________________________________________
_____________________________________________________адресы буенча яшәүче
420014, Казан шәһ., Федосеевская ур., 36 йорт адресы буенча теркәлгән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Оператор) үземнең шәхси мәгълүматларымны эшкәртергә түбәндәге шартларда рөхсәт бирәм:

1. Оператор минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүне бары тик ел саен үткәрелә торган Татарстан Республикасы муниципаль районнары авыл җирлекләре башлыклары арасында “Терлекнең баш саны артымын тәэмин итү һәм югары исәбен саклап калу”, Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар арасында “Терлекчелекне үстерү буенча иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалык”, Татарстан Республикасы крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыклары арасында “Иң яхшы гаилә терлекчелек фермасы” номинацияләре буенча республика конкурсында катнашу максатларында гына гамәлгә ашыра ала.

2. Операторга эшкәртергә бирелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге:

фамилия, исем, атасы исеме, туу датасы, паспорт мәгълүматлары, элемтә телефоны (өй, кәрәзле, эш телефоннары), гамәлдәге яшәү адресы, теркәлү адресы, булу урыны.

3. Оператор тарафыннан минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртергә, ягъни шул исәптән түбәндәге гамәлләрне кылырга рөхсәт бирәм: эшкәртергә (шәхси мәгълүматларны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, тәгаенләү (яңарту, үзгәртү), куллану, шәхси үзенчәлекләрен бетерү, блок кую, шәхси мәгълүматларны юк итү), шул вакытта югарыда күрсәтелгән мәгълүматны эшкәртү ысулларының гомуми тасвирламасы “Шәхси мәгълүматлар турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда китерелгән, шулай

ук законда билгеләнгән очракларда мондый мәгълүматны өченче затларга бирергә.

4. Әлеге ризалык чикләнмәгән вакытта гамәлдә була.

“Шәхси мәгълүматлар турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре белән таныш булуымны, шәхси мәгълүматларны яклау өлкәсендә хокуклар һәм бурычлар миңа аңлатылуын раслыйм.

____________________ ____________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

«____»______________, 20__ ел